СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Узәк урамы, 2а йорт,Түбән Аты
авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (84366)5-07-35. E-mail:Sar.Ars@tatar.ru

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 12 » март 2026 ел                                                                                    № 13

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Урта Аты авыл җирлеге Советы карар КАБУЛ ИТТЕ:

1. Урта Аты авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Арча муниципаль районының “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен раслау һәм Арча муниципаль районының “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү турында” 2017 елның 11 сентябрендәге 43 номерлы карар.

- “Арча муниципаль районының “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм Арча муниципаль районының “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль

вазыйфаларны һәм Урта Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендәге 43 номерлы карары белән расланган контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына мәгълүмат бирү турында” 2021 елның 3 августындагы 37 номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Батталова Р.Х